**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552) 3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән мәктәп автобус маршрутларын ачу турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәктәп автобусларын нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2006 елның 03 августындагы 400 номерлы карарын үтәү йөзеннән, балаларны йөртү өчен кулланыла торган автобуслар белән йөртүнең куркынычсызлыгын тәэмин иту максатларында **КАРАР БИРӘМ:**

1. Мәктәп автобус маршрутларын тикшерү актлары нигезендә, 2018 елның сентябреннән түбәндәге автобус маршрутларын ачарга:[1]

---

[1] 1.1. 1 номерлы «Татар Суыксуы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципальара махсус автобус маршруты;

1.2. 2 номерлы «Актаныш 1 нче санлы урта мәктәбе» махсус автобус маршруты (1 нче автобус);

1.3. 2 номерлы «Актаныш 2 нче санлы урта мәктәбе» муниципальара махсус автобус маршруты (1 нче автобус)

1. 4. 2 номерлы «Актаныш 2 нче санлы урта мәктәбе» муниципальара махсус автобус маршруты (2 нче автобус)

1.5. 3 номерлы «Иске Кормаш төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципальара махсус автобус маршруты;

1.6. 4 номерлы «Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципальара махсус автобус маршруты;

1.10. 8 нче номерлы «Киров урта мәктәбе» махсус муниципальара мәктәп маршруты;

1.11. 9 номерлы «Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбе» махсус муниципальара мәктәп маршруты;

1.12. «Пучы урта мәктәбе» махсус муниципальара маршруты

1.13. «Пучы урта мәктәбе» махсус муниципальара маршруты;

1.14. «Богады төп гомуми белем бирү мәктәбе» махсус муниципальара мәктәп маршруты;

1.15. «Гуманитар гимназия» махсус муниципальара мәктәп маршруты;

1.16. «Гуманитар гимназия» 14 нче номерлы махсус мәктәп маршруты;

1.17. «Гуманитар гимназия» махсус мәктәп маршруты

2. «Татавтодор» АҖ Минзәлә филиалының Актаныш ДРСУ башлыгына тәкъдим итәргә:

- юл хәрәкәте иминлеге таләпләре нигезендә автомобиль юлларын, укучыларны юл маршрутында утырту һәм төшерү пунктларын карап тотуны һәм ремонтлауны тәэмин итәргә;

- кышкы чорда юлларны регуляр чистартуны оештырырга.

3. Актаныш муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына:

- юл хәрәкәте иминлеге таләпләре нигезендә автомобиль юлларын, укучыларны юл маршрутында утырту һәм төшерү пунктларын карап тотуны һәм ремонтлауны тәэмин итәргә;

- кышкы чорда юлларны регуляр чистартуны оештырырга.

4. «Актаныш АТХ» МУП директорына тәкъдим итәргә:

- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МКУ белән килештерелгән автобус маршрутлары паспортын һәм автобусларның хәрәкәт расписаниесен раслауга тәкъдим итәргә; мәктәп маршрутларын тикшерү буенча рәсмиләштерелгән актларны тикшерү тәмамланганнан соң биш көн эчендә Башкарма комитет җитәкчесенә тапшырырга;

- расланган расписание нигезендә мәктәп автобусларын эксплуатацияләүне тәэмин итәргә;

______________________

- кимендә 3 ел эш стажы булган машина йөртүчеләрне инструктажны мәҗбүри уздыру белән сайлап алуны тәэмин итәргә;

- мәктәп автобусларын эксплуатацияләүне оештырган өчен җаваплы башкаручыларны билгеләү буенча боерык чыгарырга.

5. Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлегенең ЮХИДИ бүлекчәсе җитәкчесенә тәкъдим итәргә:

- юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә туры китереп, күрсәтелгән маршрутлар буенча мәктәп автобусларының куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча катгый контроль оештырырга.

6. Гомуми белем бирү учреждениеләре директорларына:

- балаларны торак пунктлардан база мәктәбенә кадәр, мәҗбүри рәвештә балалар исемлеген күрсәтеп җаваплы укытучыларны (озатып йөрүчеләрне) билгеләргә. Ай саен озатып йөрүче укытучылар һәм укучылар белән мәҗбүри инструктажлар уздырырга.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Н.Фәттахов